**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 23 «18» апрель 2022 ел

Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Азнакай муниципаль районының» «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге битендә һәм әлеге мәгълүматларны гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү турында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2017 елның 29 декабрендәге 40 номерлы карары (24.04.2018 № 17 карар редакциясендә) белән расланган карары үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Указы нигезендә,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Азнакай муниципаль районының» «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге битендә һәм әлеге мәгълүматларны гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү турында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы

поселогы Советының 2017 елның 29 декабрендәге 40 номерлы карары (24.04.2018 № 17 карар редакциясендә) белән расланган карары үзгәреш кертү турында, 2 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-бирешнең суммасы) хезмәткәрнең (эшченең) һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов